Мөселманны зинадан, фәхешлектән һәм башка начар гамәлләрдән сакланырга булышучы сәбәпләр

(1)

Аллаһтан курку һәм Аллаһка еш итеп догалар белән мөрәҗәгать итү. Юсуф (галяйхи ас-салям) Аллаһка шундый дога белән мөрәҗәгать иткән: "Һәм әгәр Син, Аллаһ, миннән моны ерагайтмасаң, мин аларга күнермен". Юсуф сүрәсе, 33 аять.

(2)

Аллаһның коллары Аллаһка буйсынмауны калдырган очракта, шул сәбәпле Аллаһ тарафыннан әзерләгән нәрсәләр турында фикерләү, уйлану. әйтте: "Аллаһ ﷻ Пәйгамбәребез ризалыгы өчен нәрсәне генә калдырмасаң, Аллаһ моны синең өчен яхшырак булган нәрсәгә ."алмаштырыр

(3)

Җенси әгъзалар һәм авыз белән бәйле булган теләкләр турында сөйләшүләрне калдыру. Оятсыз сүзләр һәм гамәлләрдән мәҗлесләрне чистарту, арындыру.

(4)

Мөмкинлек булу белән ук өйләнү. Әгәр мөмкинлек булмаса, ураза тоту "бу очракта ул шәһвәтен тыеп кала алыр"(Мөслим һәм Бохари җыентыкларыннан)

(5)

Ашау-эчүне киметү, чөнки алар дәртнең кимүенә сәбәп булып тора

(6)

Күз карашын түбән төшерү һәм базарлар шикелле хатын-кызлар күп булган җирләрдән ерак тору. Шулай ук чит яки махрам булмаган хатын-кыз белән берүзең калудан баш тарту.

(7)

Хатын-кызларга хиджаб кию әмере. Алар белән сөйләшкәндә йомшак тавыш кулланмау. Хатын-кыз белән берүзең калудан саклану. Алар белән кул сузып исәнләшмәү, һәм араларына кереп кушылмау.

(8)

Юсуф сүрәсен уку, һәм аның (аңа Аллаһның сәламе булсын) тарихы турында фикерләү. Шулай ук Коръәндә булган калган хикәяләр һәм алдагы булган сәләфләрнең тормыш юллары турында уйлап гыйбрәтләну.

(9)

Яхшылыкка өнди торган һәм начарлыктан сак тотучы тәкъвалы кешеләр белән аралашу, һәм явызлыкка һәм гөнаһларга өндәүчеләрдән ерак тору.

(10)

"Син ничек хөкем кылсаң, сиңа да шулай хөкем кылыныр" дигән кагыйдәне истә тоту. Зина кылу – ул кайтарасы бурыч.

(11)

Файда китерүче нәрсәләр белән шөгыльләнү, эшсезлектән баш тарту. Чынлыкта эшсезлек нәлакәткә китерә. Чөнки эшсезлек аркасында кеше начар гамәлләргә этәрә торган җаны белән һәм шәйтан белән берүзе кала.

(12)

Шәһвәтне көчәйтә торган һәм фәхешлеккә этәрә торган яңа техник чараларыннан һәм анда булган төрле программалардан (приложения) саклану.

(13)

Компьютерлар һәм телефоннарны калганнарның күзләренә күренә торган урынга кую, урнаштыру. Чөнки, әйтелгәнчә, кеше үз-үзе белән калган очракта зәгыйфьләнә.

(14)

Ислам диненең йоласыннан булып торган – башкаларны начар гамәлләр кылудан тыю. Әгәр моны булдыра алмасаң йөрәгең белән бу гәмәлләргә килешмәү. Чөнки бу йөрәкне җанландыра һәм яхшы гамәлләргә этәрә.